*/Мәктәп тормышы/*



### Бакча төркемендә ТУГАН ТЕЛ көне

Туган Тел көненә әзерләнү күңелгә башка төрле тәэсир итә. Ничектер үзенчәлеклерәк, үтемлерәк ясыйсы килә. Шуңа күрә дә бәйрәм үтәчәк залны милли стильдә биздек. "Татар халык ашлары", "Чигүле кульяулыгым", "Татар халык киемнәренә – уен", "Төрле милләт халыклары киемнәре" дип аталган күргәзмәләр булдырдык.

Иң элек мәктәпкәчә яшьтәге балаларның туган телгә багышланган шигырьләрен тыңладык. Шулай ук кунакка килүче апалар һәм укучы балаларның шигырьләрен тыңлап мавыктык. Авыл китапханәчесе Рузилә апалары балаларга- милли ризыклар турында, мәктәп китапханәчесе Рузалия апалары милли киемнәр турында чыгыш ясадылар.

Чыгышлардан соң балаларны "Йөзек салыш", "Әйлән бәйлән" кебек милли уеннар уйнадылар. Ахырдан берсеннән-берсе тәмле милли ризыклар белән балалар чәй эчте.

*Каусәр Насыйрова, VII сыйныф укучысы*



### Китап бүләк итешик!

2012 елдан башлап 14 февраль – Халыкара китап бүләк итү көне (International Book Giving Day) буларак билгеләп үтелә. Әлеге көн балаларга китап бүләк итүчеләрне һәм укуга мәхәббәт тәрбияләүчеләрне берләштерә. Китап бүләк итүне махсус рәвештә билгеләп үтү америкалы Эмми Бродмур тәкъдиме белән башлана. Без аны АКШта балалар китабының тәүге сайтын ачучы буларак беләбез.

Китап бүләк итү көненең әһәмияте"Халыкара" исемен йөртүенә генә бәйле түгел. Укырга яратып та, тегe яки бу сәбәп аркасында үзләре сатып ала алмаган балаларга китап бүләк итү, чыннан да, мактауга лаеклы гамәл.

Безнең мәктәптә дә Халыкара китап бүләк итү көне билгеләп үтелде. Китапханәче Рузалия апа укучыларның бер-берсенә китап бүләк итүләрен оештырды. Бүләк ителгән китаплар киштәдә генә калмыйча, укылып, кулдан-кулга йөрсен иде дигән теләктә калыйк.

*Настя Сафеева, VII сыйныф укучысы*

### Дәрестән тыш чараларда

**"Россия мәктәпләрендә кинодәрес"** проектын тормышка ашыру кысаларында, мәктәбебез укучылары "Могҗизалы яңа ел" фильмын карадылар. Фильм геройлары бик үтемле итеп яхшылык эшләү могҗиза тудырганлыгын аңлатты. "Җиңү эзтабарлары" киносында Бөек Җиңүгә багышланган тема яктырдылды. "Дуслар авырлыкта ялгыз калдырмыйлар" киносы чын дуслыкның нигезен ятыртты. "Шайба" киносы кыюлык, җаваплылык, башлаган эшне ахырына җиткерү турында иде.

Һәр каралган фильм яшь буын вәкилләрендә югары әхләкый сыйфатлар тәрбияләүгә багышланган. Бергәләшеп караган кинолар һәм шулар буенча ясалган нәтиҗәләр эзсез югалмас дип ышанасы килә.

1999 елдан бирле 8 февраль **Россия фәне көне** дип билгеләп үтелә. 1724 елның 8 февралендә Петр I фәрманы буенча Петербург фәннәр академиясенә нигез салына. 1925 елда ул СССР фәннәр Академиясе дип, ә 1991 елда Россия фәннәр Академиясе дип үзгәртелә. Әлеге истәлекле дата уңаеннан мәктәптә тәрбия сәгатьләре уздырылды. Аларда илебез галимнәренең хезмәте, шул исәптән, милләттәш галимнәребезнең казанышлары турында сөйләнде. Нобель премиясе лауреатлары турында да мәгълүматлар китерелде.

15 февраль көнне ел саен батыр милләттәшебез, каһарман шагыйрь **Муса Җәлилнең туган көнен** билгеләп үтәбез. Иҗатының тирән эчтәлегенә, "Моабит дәфтәрен"дәге шигырьләренә сокланабыз. Шул уңайдан Россиякүләм иҗади эшләр бәйгесендә катнашып, **Самат Гафиятуллин** II урын яулады.

Шулай ук, бу көн Россиядә **интернационалист сугышчыларны искә алу көне** буларак билгеләп үтелә. Совет гаскәрләренең Әфганстаннан чыгарылуына быел 36 ел тула. Әлеге истәлекле даталар уңаеннан да бу көнне сыйныф сәгатьләре үткәрелде.

*Олеся Пискарева, директор киңәшчесе*

*/Котлыйбыз!/*



Февраль аенда дөньяга килгән дусларыбыз – IV сыйныфтан **Камалов Илнур** (10.02), VI сыйныфтан **Донсков Артур** (8.02) белән **Хәбибрахманов Абдулланы** (3.02), VIII сыйныфтан **Хусенов Стасны** (27.02), IX сыйныфтан **Йосыпов Рәсимне** (14.02) туган көннәре белән котлап, ныклы сәламәтлек, укуларында зур уңышларга ирешүләрен телибез.

Башлангыч сыйныф укытучысы **Закирова Гөлшат апаны** да туган көне белән котлап, тормыш иминлеге, сәламәтлек, эшендә уңышлар теләп калабыз.

**Газетаны гамәлгә куючы** – Түбән Майна урта мәктәбе
**Мөхәррир** – Фәнүзә Гафиятуллина
**Редколлегия әгъзалары:** Зәйнәп Нурматова, Самат Гафиятуллин, Каусәр Насыйрова, Ләйсән Закирова, Мәдинә Әхсәнова, Камил Төхвәтуллин



# Мәктәп хәбәрчесе

**№2**
**(№63)**
**февраль 2025 ел**

*Түбән Майна урта мәктәбе гәзите*



Тел. 8 (84344) 4-38-46 sch1644maina@mail.ru




*/ Мөгаллим киңәше/*

### Ватан кайдан башлана?

2025 ел ил халкы өчен истәлекле даталарга бик бай. Шуларның иң әһәмиятлесе - Бөек Җиңүнең 80 еллыгы. Шуңа бәйле рәвештә Россия Президенты **Владимир Путин** 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итәргә тәкъдим итте.

Нәрсә ул Ватан ? Ул кайдан башлана соң?

Ватан – ул без яшәгән авыллар һәм шәһәрләр, иксез-чиксез кырлар, урманнар, чиста сулы елгалар, челтерәп аккан чишмәләр, биек таулар. Ул безнең белем алган мәктәбебез дә. Ул безнең тирә-күршеләребез. Гомумән, без сулаган һава, без аяк баскан чирәм дә, без бергә уйнаган дуслар да.

Кеше бу дөньяга килү белән үзенең иң зур байлыгын – Ватанын мираска ала. Ул - Ходай биргән гомеребез кебек бер генә! Аны үзгәртеп тә, алмаштырып та, яңартып та булмый. Әти-әнине сайлап булмаган кебек, син, Ватаныңны да сайлап ала алмыйсың.

Ватан яшәсен өчен, аны сакларга кирәк. Ил сагында кораллы көчләр, чик буе гаскәрләре тора. Дошман үтеп кермәсен өчен ир-егетләребез гел сакта, уяу булырга тиеш. Алар безнең тыныч тормышыбызны саклыйлар.

Солдатлар үз бурычларын намус белән башкарсын өчен бездән дә, хәлебездән килгәнчә тырышу таләп ителә. Тырышып укырга, тәрбияле, физик һәм рухи яктан көчле, максатчан булырга кирәк. Туган илнең үткәнен, тарихын белергә, өлкәннәрне хөрмәт итәргә өйрәнергә кирәк. Үткәнен белмәгән халыкның киләчәге булмас, ди танылган галимебез Ризаэтдин Фәхретдин. Туган телнең, туган нигезнең кеше тормышында нинди әһәмияткә ия булуын кечкенәдән аңлап үсәргә, аларны сакларга, якларга өйрәнергә кирәк. Болар барысы да Ватанны саклау дип уйлыйм мин.

Быел Бөек Җиңүгә 80 ел була. Безнең арада сугыш ветераннары күптән юк инде. Шулай да безнең авылларда сугыш елы балалары бар. Аларның һәрберсе үзе бер тарих. Шул әби-бабайлар үзләрен кызганмайча төрле эшләрдә эшләп Җиңүне якынайткан кешеләр. Аларга хөрмәтебез һәрвакыт зур булырга тиеш. Укучыларыбызга гамәлләр аша Ватанны яратырга, аны сакларга кирәклеген, үткәнебезне барлап, аны онытырга ярамаганлыгын тәрбияләргә тырышабыз. Олы Ватанга мәхәббәт шушы аяк басып атлап киткән Кече Ватаннан башланганын истә тотарга иде.

Шул уңайдан егетләребезне Ватанны саклаучылар көне белән котлап китәсем килә. Хәрби хезмәттә генә түгел, Ватаныбызны һәр минут сакларлык шәхесләр булсагыз иде. Укуда алдынгы, тырыш булу, телеңне, милләтеңне, динеңне саклау кебек изге бурычларны чын күңелдән үтәрлек рухи яктан көчле кешеләр булыгыз! Гаиләгезне, авылыгызны, төбәгегезне чын күңелдән яратып, милләттәшләрегезнең горурлыгы булыгыз!

*Рифкать Туктамышев, VI сыйныф җитәкчесе*




*/ Безгә кунак килде/*

### Батырлык дәресе

Ватанны саклаучылар көне уңаеннан ел саен мәктәпләрдә "Батырлык дәресе" үткәрелә. 15 февраль көнне бу дәрес безнең мәктәптә дә булды. Әлеге дәреснең кунаклары Аксубай районының "Россиягә хезмәт итәм" хәрәкәте ветераннары иде. Укучылар һәр ветеранның чыгышын тын да алмыйча тыңладылар. СВО зонасыннан кайтарылган экспонатлар күргәзмәсе оештырылганга бигрәк тә мавыктыргыч булды ул. Укучылар экспонатларны карап кына калмадылар, ә үзләрендә дә сынап карадылар. Шулай ук балалар фронтовикларның тормышы һәм көнкүреше турында бик күп мәгълүмат та ишеттеләр. Бигрәк тә хәрби операция кырыннан кайткан имзалы флаг беркемне дә битараф калдырмады. Соңыннан кунаклар безгә гитарада уйнап батырлык турында җырлар башкардылар.

Без ветераннарга һәм волонтерларыбызга ихлас рәхмәтебезне белдерәбез!

*Настя Сафеева, VII сыйныф укучыс*

*/Безнең бәйрәмнәр/*




## *Ватанны саклаучылар көне*

Быелгы Ватанны саклаучылар көнен ярыш формасында үткәрдек. Иң башта апалары Ватан төшенчәсенең мәгънәләрен аңлаттылар. Ватанны саклау – ул илнең чигендә корал тотып яклау гына түгел, ә гаиләңне, туганнарыңны, авылыңны ярату да. Шулай ук, телеңне, милләтеңнне, динеңне саклау да Ватанны саклау икәнен аңладык.

Бәйрәмнең икенче өлешендә без, башлангыч сыйныф малайлары, үзебезне төрле яктан күрсәттек. Укытучы апалар кызыклы конкурслар уйлаганнар иде. Шнур бәйләүдән башлап, мылтыктан ату буенча да ярыштык. Аннан соң һәрберебез үзебез уйлап тапкан танк рәсемнәрен ясадык. Сыйныфташ кызларыбыз безнең җанатарлар һәм бәяләүчеләребез булып тордылар. Ярыш нәтиҗәләре белән таныштырганнан соң, кызлар Ватанны саклау турында җыр җырладылар, бүләкләрен тапшырдылар. Ә укытучы апалар безнең фотолар төшерелгән кружкалар бүләк иттеләр. Мин хәзер чәйне шул кружкадан гына эчәм.

***Инсаф Закиров, IV сыйныф укучысы***

## *“Алга” алдынгы булды*

Ватанны саклаучылар көне – егетләр өчен сынау көне инде ул. 5-11 сыйныфларда укучы малайлар 22нче февраль көнне ярыш оештырдылар. “Алга” һәм “Йолдыз” командаларына бүленеп, үзләрен физик һәм белем ягыннан сынадылар.

Ярыш Ватаныбыз тарихына кагылышлы сорауларга җавап табу бәйгесе белән башланды. Аннан соң егетләр хәрби-спорт төрләре буенча көч сынаштылар. Җыелган баллар буенча, “Алга” командасы, исеменә тугры калып, җиңү яулады. “Йолдыз” командасы берничә баллга арттарак калды. Ярыш нәтиҗәләре егетләргә белемнәр буенча да, физик яктан да көчләрен арттырыру кирәклеген күрсәтте.



***Гөлсем Сафиуллина, IV сыйныф укучысы***

*/Безнең спорт/*



16 нчы февраль көнне Чистай шәһәре шахмат чемпионатында безнең VIII сыйныф укучысы **Гафиятуллин Фаил** рапид төре буенча ир-атлар арасында I урынны алуга иреште.

22 нче февраль көнне Норлат шәһәрендә Әфганистан республикасында интернациональ бурычын үтәгәндә һәлак булган якташыбыз Миншакир Бакиров һәм махсус хәрби операциядә һәлак булган якташлар истәлегенә багышланган бибау көрәше буенча ярыш уздырылды.Безнең VIсыйныф укучысы **Җамалетдинов Зөлфәт** бу бәйгедә үз авырлыгында III урынны яулады. Ярышта катнашкан башка көрәшчеләребез, көчле көндәшләр күп килү сәбәпле, бу юлы призлы урыннарга чыга алмадылар.

28 февральдә “Россия чаңгычылар көне”уңаеннан һәр елны илкүләм күмәк чаңгыда йөгерү уздырыла. Безнең мәктәп өчен дә бу көн искәрмә булмады. Укучыларыбыз кечесеннән олысына кадәр бу чарада актив катнаштылар. Укучыларыда актив спортка карата мәхәббәт тәрбияләү, сәламәтлегеңне кайгырту, телефон экранынннан бераз булса да аерылып тору максатын күздә тота бу чара.

Әйтергә кирәк, кышның һәр көнен “чаңгычылар көне” иту барыбызның да хәленнән килә. Әти-әниләребезнең бала чагында шулай булган бит.Сөйләүләре буенча, алар кыш буена мәктәптән тыш вакытларын чаңгы һәм тимераякта шуып уздырганнар.



*/ Безнең уңышлар/*



## *ТУГАН ТЕЛ көне уңышлары*

21нче февраль – Халыкара Туган Тел көне буларак билгеләп үтелә. Бу чара уңаеннан ел саен укучылар арасында нәфис сөйләм бәйгесе уздырыла. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр дә, башлангыч, урта һәм югары сыйныфлар да монда актив катнаша.

Шул бәйрәм чарасының дәвамы булып, без район мәгариф бүлеге үткәргән Туган Тел көнендә дә катнаштык. 27нче февраль көнне Хәсән Туфан иҗаты буенча бәйге һәм Туган телләр көне бер чара кысаларында билгеләп үтелде. Без ике юнәлешкә катнашырга да өлгердек. Хәсән Туфанның “Бу елларда мин дә шулай инде” шигырен сөйләп, **Вәлиев Ибраһим** җиңүче булды. Аның сөйләме, сәхнәдә үзен тотуы меңнәр арасыннан да аерылып торырлык иде. Ә инде III сыйныф укучысы **Гафиятуллина Руфинә** призер исеменә лаек булды. Балалар бакчасында тәрбияләнүчеләр арасындагы ярышта **Сафиуллин Ислам** җиңүче исеменә лаек булды. Ислам да үз сөйләме белән тамашачыларны җәлеп итте.

Әдәби чараларда катнашканда укучының сөйләме өчен шатлану – иң зур бүләктер. Әйе, безнең укучыларның Ана телебездә сәнгатьле сөйләме башкалар белән чагыштырганда уңай якка аерылып тора. Бәйгедә катнашкан татар телле булырга тиешле балаларның теле русча сөйләм белән буталганга, авазлары рус теленә якын яңгыраганга күңелләр генә төшеп кайтты. Милләтебезнең асыл балалары упкынга тәгәрәгән кебек тәэсир калды. Исхакыйның “Ике йөз елдан соң инкыйраз”ы искә төште. Шул кимчелекләрне вакытында күреп, хаталарыбызны төзәтергә өлгерсәк иде.

***Фәнүзә Гафиятуллина, татар теле һәм әдәбияты укытучысы***

## *Иҗади бәйгеләр*



Февраль аенда районда Ватанны саклаучылар һәм Туган Тел көннәренә багышланган чаралар күп уздырылды. Хәсән Туфан елына багышланган рәсем конкурсларында **Нурматова Асия** I урынны, **Сафиуллина Гөлсем** белән **Хәбибрахманова Хәнифә** призёр исеменә лаек булдылар. Иншалар конкурсында **Гафиятуллин Самат** җиңүче исемен алуга иреште.

Z-патриот конкурсында **Хәбирахманова Асия** рәсеме I урынга, **Насырова Кәүсәр** белән **Сафиуллина Кәримә** җиңүче исемнәренә ия булдылар.

**Хәбибрахманова Хәнифә** «Животный мир глазами детей. Haliotis» республикакүләм рәсем конкурсының беренче турында җиңүче буларак, КФУның Э.А.Эверсман исемендәге зоологик музеенда уздырылган икенче турында катнашып кайтты.

Укчыларыбыз иҗади яктан көчле, димәк, киләчәктә дә бу юнәлештә эшләргә, урыннар алып, үзегезнең сәләтләрегезне күрсәтергә.

## *Укычыбыз өчен рәхмәт хаты*



алабуга

Благодарственное письмо

ВРУЧАЕТСЯ

Директору

МБОУ «Нижнетатмайнская СОШ»

Аксубаевского района

Выражаем благодарность за отличную подготовку сотрудника АО «ОЭЗ ППТ «Алабуга» и выдающиеся достижения в обучении и воспитании ученика. Ваш выпускник демонстрирует глубокие знания, профессиональные навыки и высокую трудовую этику, что является свидетельством Вашего педагогического мастерства и преданности своему делу.

Руководитель группы проектов АО «ОЭЗ ППТ «Алабуга» Замятин А.А.

2024 елны мәктәпне тәмамлаган укучыбыз Хәйруллин Айназ һөнәри белем алу өчен Алабуга шәһәрендәге “Алабуга Политех” мәгариф үзәгенә укырга кергән иде. Билгеле булганча, әлеге уку йорты студентлары һөнәр үзләштерүне сәнагать-җитештерү тибындагы махсус икътисади зонада хезмәт итү белән бергә алып баралар. Инде менә Айназ мәктәпкә кунакка килеп, сабакташлары белән очрашу уздырды. Чыгышында ул үзе белем алган мәгариф үзәгендәге уку һәм хезмәт шартлары белән таныштырды. Иптәшләренең сорауларына җавап бирде.

Айназ мәктәпкә буш кул белән килмәгән иде, безгә ул “Алабуга Политех”җитәкчелегенең Рәхмәт Хатын тапшырды.

Әлеге хатта түбәндәге юллар китерелә:

“Сезнең мәктәп укучысының тирән белемнәр, һөнәри күнекмәләр һәм югары хезмәт этикасына ия булуы үз эшегезгә бирелгәнлек һәм педагогик осталыгызның нәтиҗәсе булып тора. “ОЭЗ ППТ “Алабуга” хезмәткәрен укыту һәм тәрбияләүгә ирешкән югары күрсәткечләрегез өчен Сезгә ОЛЫ РӘХМӘТЕБЕЗНЕ белдерәбез”.

***Ләйсән Закирова, VII сыйныф укучысы***